ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

23 сентябрь, 2020 ел № 1/13

Аерым муниципаль учреждениеләр
җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең
хезмәтенә түләү шартлары турында
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 5 августындагы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 655 номерлы Карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә ( Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10, 2019 елның 23 маендагы 31/6 номерлы, 2020 елның 6 февралендәге 36/5 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 2.2 бүлек белән тулыландырырга:

« 2.2.бүлек «Янгын-коткару отряды» Муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең аерым категорияләренә хезмәт өчен түләү

15.1. Әлеге бүлек «Янгын-коткару отряды» Муниципаль бюджет учреждениесенең түбәндәге хезмәткәрләренең хезмәт шартларын җайга сала: җитәкче, баш хисапчы, каравыл башлыгы, янгын бүлеге командиры, янгын сүндерү машинасы йөртүчесе (алга таба - учреждение хезмәткәрләренең аерым категорияләре).

15.2. Учреждениенең аерым категория хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары 1 нче таблицада китерелгән:

1 нче таблица

Учреңдениенең аерым категория хезмәткәрләрнең
вазыйфаи окладлары

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җитәкче | 17 716 |
| Баш хисапчы | 12 401 |
| Каравыл башлыгы | 12 734 |
| Янгын сүндерү бүлеге командиры | 11 844 |
| Янгын сүндерү машинасы йөртүчесе | 9026 |

15.3. Учреждениенең аерым категория хезмәткәрләре өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

15.4.Кызыксындыру характерындагы түләү төрләренә керә:

1) эшнең интенсивлыгы  һәм югары нәтиҗәләр өчен түләүләр;

2) тиешле еллар эшләгән өчен түләүләр;

3) эш йомгаклары буенча премиаль түләүләр;

4) матди ярдәм.

15.5. Кызыксындыру характерындагы түләүләр, әгәр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында башкача билгеләнмәгән булса, окладларга (вазыйфаи окладларга, тариф ставкаларына) (алга таба - оклад)  өстәмәләр  рәвешендә билгеләнә.

15.6. Даими нигездә билгеләнә торган эш интенсивлыгы һәм югары нәтиҗәләр өчен түләүләр:

1) хезмәткәрләргә аерым хезмәт шартлары (оператив-техник әзерлекнең югары дәрәҗәсен тәэмин итү, махсус эш режимы, эшнен катлаулылыгы, киеренкелеге һәм аерым хезмәт шартлары) өчен өстәмә  − окладның 50 процентына кадәр;

2) икенче класслы автомобиль йөртүчеләргә бирелгән квалификация категориясенә өстәмә − окладның 10 проценты, беренче класслы автомобиль йөртүчеләргә −  окладның 25 проценты.

15.7. Тиешле еллар эшләгән өчен түләүләр ай саен тиешле еллар эшләгән өчен процент өстәмәсе рәвешендә башкарыла (алга таба − процент өстәмәсе) һәм 2 нче таблица нигезендә окладларга (вазыйфаи окладларга, тариф ставкаларына) кушып  исәпләнә.

2 нче таблица

Тиешле еллар эшләгән өчен түләү

| Стаж дәвамлылыгы | Өстәмә түләү күләме, процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 3 елга кадәр | 5 |
| 3 елдан 5 елга кадәр | 10 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 20 |
| 15 елдан артык | 30 |

15.8. Эш нәтиҗәләре буенча премиаль түләүләр:

1) премия түләү билгеле бер чорда (ай, квартал, агымдагы елның башка чорында) эш нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла;

2) учреждение хезмәткәрләренең аерым категорияләренә календарь ел йомгаклары буенча вазыйфаи (хезмәт) бурычларын намус белән башкарган өчен ике оклад күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк (премия) (алга таба – еллык премия) түләнә.

15.9. Әлеге Нигезләмәнең 15.8 пунктындагы 1 пунктчасында каралган премияне түләү тәртибе һәм шартлары учреждение җитәкчесе тарафыннан расланган нигезләмә белән билгеләнә. Учреждение хезмәткәрләренең аерым категорияләренә премиянең конкрет күләме учреждениенең хезмәт өчен түләү фонды чикләрендә билгеләнә.

Әлеге Нигезләмәнең 15.8 пунктындагы 2 пунктчасында каралган еллык премия хезмәткәрләрнең үз вазыйфаи (хезмәт) бурычларын үз вакытында һәм сыйфатлы башкаруда матди кызыксынучанлыгын тәэмин итү, йөкләнгән эш участогы өчен җаваплылыкны арттыру максатларында түләнә. Хезмәткәргә еллык премия календарь елының 1 декабренә үзе биләгән вазыйфасы (һөнәре) буенча фактта билгеләнгән ике оклад (вазыйфаи окладлар) күләмендә, хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә түләнә.

Әлеге Нигезләмәнең 15.8 пунктында каралган премиаль түләүләрнең конкрет күләме Башкарма комитет билгеләгән тәртиптә билгеләнә.

15.10. Отпускка бер оклад (тариф ставкасы) күләмендә матди ярдәм түләү хезмәткәргә чираттагы ял биргәндә башкарыла.

15.11.Календарь ел дәвамында кабул ителгән (тулы календарь ел эшләмәгән) учреждение хезмәткәрләренең аерым категорияләренә матди ярдәм түләү әлеге календарь елында эшләнгән тулы айлар санына пропорциональ рәвештә башкарыла. Алдагы елда чираттагы ял биргәндә (11 айдан соң) матди ярдәм эш елының калган айлары өчен түләнә.

15.12. Учреждение хезмәткәрләренең аерым категорияләренә компенсация характерындагы түләүләрнең түбәндәге төрләре билгеләнә:

1) зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка махсус хезмәт шартлары белән авыр эшләр башкарган өчен;

2) нормаль эштән читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны ) берләштергәндә, эш вакытыннан тыш, төнлә һәм нормаль эштән читләшкән башка шартларда) эшләр башкарган өчен.

15.13. Кызыксындыру характерындагы түләүләр, Россия Федерациясе законнарында һәм норматив хокукый актларында башкача билгеләнмәгән булса, окладларга (вазыйфаи окладларга, тариф ставкаларына) (алга таба - оклад) өстәмәләр рәвешендә билгеләнә.

15.14. Нормаль эштән читләшкән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны ) берләштергәндә, эш вакытыннан тыш, төнлә һәм нормаль эштән читләшкән башка шартларда) эшләр башкарган өчен эшләрне башкаруның фактагы вакытына түләүләр:

1) төнге вакытта эшләгән өчен төнлә эшләгәннең һәр сәгатенә каралган сәгатьлек тариф ставкасының 35 проценты исәбеннән өстәмә түләнә;

2) ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә эшләгән өчен өстәмә ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәрендә эшкә җәлеп ителүче хезмәткәрләргә түләү законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла;

3) эш вакытыннан тыш эшләгән өчен арттырылган түләү беренче ике сәгать эчендә бер ярым күләмнән ким булмаган күләмне, аннан соңгы сәгатьләрдә - Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 152 статьясы нигезендә икеләтә күләмнән ким булмаган күләмне тәшкил итә.»;

2) 17 пунктта «11 163» санын «11 498» санына алыштырырга;

3) 21-21. 2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесеннән тыш, аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициентлары:

| Вазыйфа исеме | Арттыру коэффициенты (вазыйфаи окладның проценты) | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| Оешма җитәкчесе | 2,25 | 25 871 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары | 2,0 | 22 996 |
| Бүлек башлыгы | 1,65 | 18 972 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 1,55 | 17 822 |
| Баш белгеч | 1,4 | 16 098 |
| Әйдәүче белгеч | 1,17 | 13 453 |
| I категорияле белгеч | 1,12 | 12 878 |
| II категорияле белгеч | 1,1 | 12 648 |
| Белгеч | 1,08 | 12 418 |

21.1. «Яр Чаллы шәһәре муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» Муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме:

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| Җитәкче | 28 634 |
| Җитәкченең беренче урынбасары; җитәкче урынбасары | 26 986 |
| Бүлек башлыгы | 21 115 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 19 004 |
| Баш белгеч | 17 304 |
| Әйдәүче белгеч | 15 759 |

21.2 Аерым муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган арттыру коэффициенты:

| Вазыйфа исеме | Коэфффициент | Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинкада басу бюросы мөдире, күчермәләр ясау - күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статистик, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографист, секретарь-стенографист, машинист, экспедитор, секретарь-машинистка, җитәкче секретаре, таксировщик, участок мастеры (шул исәптән өлкән мастер)» | 1,0 | 11 498». |

2. Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге «Хезмәткә түләүнең яңа системасы кертелгән муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре өчен хезмәт өчен түләү шартларын билгеләү турында» 39/8 номерлы Карарының (Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге 9/8, 2016 елның 15 декабрендәге 13/9, 2017 елның 29 мартындагы 16/6, 2017 елның 10 августындагы 18/5, 2018 елның 21 февралендәге 23/8 номерлы Карарлары редакциясендә) 1 пунктындагы 6 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Карар 2020 елның 1 октябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тоту Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев